# “Юл йөрү кагыйдәләре буенча дидактик һәм хәрәкәтле уеннар”



*Әзерләделәр: Нәфыйкова Айсинә Галим кызы*
*Яруллина Нурсинә Мисбах кызы*
*Гатауллина Гелия Ибраһим кызы*

# *“Киселгән юл билгеләрен җый”*

- **Максат:** Балаларга юл билгеләрен өйрәтү, уен аша һәтердә ныгыту.
- **Бурычлар:** Юл билгеләрен төрләре буенча танып белүне ныгыту һәм камилләштерү, балаларда игътибарлылык, уйлау, күзәтүчәнлек тәрбияләү.
- **Уен барышы:** Балалар өч төркемгә бүленәләр, аларга киселгән юл билгеләре бирелә, беренче төркем – җәяүлеләр юлын; икенче төркем – велосипед юлын; өченче төркем – автобуслар тукталышын (остановка) җыялар. Кайсы төркем тизрәк җыя һәм аңлатып бирә.




Originals
Surfing






Originals
Surfing

# “Светофор уены”

- **Максат:** Балаларга светофор турында төшенчә бирү, уен аша светофорның сигналларын белүне ныгыту.
- **Бурычлар:** Балаларда игътибарлылык, урамда, борылышларда, машина хәрәкәте урыннарында үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләрен, светофорның яшел, кызыл, сары сигналлары турында белемнәрен ныгыту, кабатлау, фикерләү сәләтен үстерү.
- **Уен барышы:** Балалар түгәрәккә басалар. Татар халык бию көе куела, тәрбияче яшел төс күрсәтә – балалар түгәрәк буйлап биеп баралар. Сары төс күрсәтә – урыннарда ббииләр. Кызыл төс күрсәтә – туктап калалар.











# *“Транспорт төрләрен аер”*

- **Максат:** Транспорт төрләре турында төшенчә бирү: су, һава, җир транспорты.
- **Бурычлар:** Транспортны кулланышы ягыннан аера белергә өйрәтү. Транспортның төп өлешләрен чагыштыра белү күнекмәләрен формалаштыру. Гомуми сөйләм күнекмәләрен, хәрәкәт һәм сөйләм координаөиясен камилләштерү.
- **Уен барышы:** Балалар өч төркемгә бүленә, һәр төркемгә төрле транспорт рәсеме бирелә. Шул рәсемгә туры китереп беренче төркем – җирдә йөрүче транспортларны җыя, икенче төркем – һавада очучы транспортларны җыя, өченче төркем – суда йөзүче транспортларны җыя (балалар эше). Җыеп бетергәч һәр төркемнән нинди транспорт төре җыюларын әйтәләр һәм кара-каршы алыштырышалар.






БУДЬТЕ
ОСТОРОЖНЫ
НА ДОРОГЕ!

